| УПРАВЛЕНИЕ<br>ПО ОХРАНЕ И<br>ИСПОЛЬЗОВАНИЮ<br>ОБЪЕКТОВ<br>ЖИВОТНОГО МИРА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ<br>ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ<br>ҺӘМ АЛАРДАН<br>ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

**Приказ** **Боерык**

__________2016 г. г. Казань № ______

Сәнәгый балык тотуны булдыру
өчен, балык тоту бүлемтекләрен
куллануга килешүнамә төзү буенча
дәүләт хезмәтен күрсәтүнең
Административ регламентын
раслау турында

2014 елның 1 декабреннән 419-ФЗ номерлы "Инвалидлар хокуклары турындагы Конвенцияне ратификацияләү белән бәйле рәвештә, инвалидларны иҗтимагый яклау сораулары буенча, Россия Федерациясенең аерым кануннарына үзгәрешләр кертү турында"гы Федераль канун белән, 2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы Федераль канун белән, 2010 елның 2 ноябреннән "Татарстан Республикасының башкарма хакимият әгъзаларының хезмәт күрсәтүләре буенча адмистратив регламентларны эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгешләр кертү турында"гы 880 номерлы Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының карары белән тәңгәл килеп

**боерам**:

1. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенең 2012 елның 24 июненнән 199-од номерлы "Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзүнең Административ регламентын раслау турында"гы боерыкны көчен югалткан дип санарга.

2. Бирелгән Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ

регламентын расларга

3. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы  объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгы урынбасарына, дәүләт хезмәте күрсәтүче затларга, Регламент кагыйдәләрен тайпылышсыз тотарга.

4. Хайваннар дөньясы объектларын файдалануны лицензияләү, исәпкә алу, тәртипкә, рәткә салу, кадастр бүлеге башлыгы Р.Э. Чиспияковка, регламентны “Татарстан Республикасының рәсми порталы” исемендәгеТатарстан Республикасының мәгълүмати системасы катнашмасына керә торган, Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы  объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенең рәсми сайтында урнаштырырга

5. Хайваннар дөньясы объектларын файдалануны лицензияләү, исәпкә алу, тәртипкә, рәткә салу, кадастр бүлеге  башлыгы Р.Э. Чиспияковка, бу боерыкның дәүләт теркәвен ясарга.

6. Алдынгы киңәшче В.В. Фугинга, Регламентны  Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Реестрына кертү өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 10 сентябреннән 729 номерлы “Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Реестры” исемле дәүләт мәгълүмати системасы турындагы Кагыйдәнамә белән тәңгәл килеп,юнәлтүне тәэмин итәргә.

7. Боерыкның үтәлүе артыннан тикшерүне Татарстан республикасының хайваннар дөньясы  объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгы урынбасары Ю.Б.Матвеевка тапшырырга.

Идарә башлыгы Ф.С.Батков

____2016 елдан___номерлы
Татарстан республикасының
хайваннар дөньясы
объектларын
саклау һәм файдалану
Идарәсе Боерыгы белән
расланган

**Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең**

**Административ регламенты**

## 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе белән, сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламенты ( алга таба – регламент) сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели ( алга таба – дәүләт хезмәте)

1.2. Дәүләт хезмәтен алучы - Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү хокукын алу өчен бәйгедә җиңүче (Россия Федерациясенең 14.04.2008 елдан 264 номерлы боерыгы белән расланган, сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү хокукын алу өчен бәйгене оештыру һәм уздыру кагыйдәләре белән билгеләнә)(алга таба – бәйге җиңүчесе).

1.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче булып Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе килә ( алга таба – Идарә).

1.3.1. Идарәнең урнашу урыны: Казан, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт.

Идарәнең эш вакыты: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

Иҗтимагый транспорт белән “Татарстан” тукталышына кадәр :
автобуслар № 1, 31, 53, 54, 6, 71;
троллейбуслар №3, 5;
«Ахтямов» тукталышына кадәр:
автобуслар № 23,5, 56, 68, 71, 72.

Керү шәхесне раслый торган документ буенча.

1.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны белдерү Хайваннар дөньясы объектларын файдалануны лицензияләү, исәпкә алу, тәртипкә,

рәткә салу, кадастр бүлеге алып бара (алга таба – бүлек). Тел.: (843) 211-70-78.

1.3.3. Мәгълүмати-телекомммуникатив “Интернет” челтәрендә, “Татарстан Республикасының рәсми порталы” исемендәге Татарстан Республикасының мәгълүмати системасы катнашмасына керә торган, Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенең рәсми сайт адресы http://www.ojm.tatar.ru, электрон почта адресы ojm@tatar.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты һәм “Интернет”челтәре).

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Идарә биналарында дәүләт хезмәте турында турыдан-туры күреп һәм текстлы мәгълүмат булган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар ярдәмендә ;

2) “Интернет” челтәре аша:

Идарәнең рәсми сайтында (http://www.ojm.tatar.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/);

3) Идарәгә телдән мөрәҗәгать итеп ( телефон аша яки шәхси);

4) Идарәгә язмача мөрәҗәгать итеп (шул санда Идарәнең рәсми сайты ярдәмендә җибәрелгән электрон документ аша).

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү сораулары буенча мәгълүмат, Җүлек белгечләре белән Идарәнең рәсми сайтында һәм Идарә биналарының мәгълүмати стендларында урнаштырыла.

Мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат, дәүләт хезмәте турында, бу Регламентның .1, 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында бирелгән мәгълүматны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге актлар белән җайга салына:

20.12.2004 ел. №166-ФЗ “Балыкчылык һәм биологик су байлыкларын саклау турында”гы Федераль канун белән ( алга таба – 166-ФЗ номерлы Федераль канун)( 23.12.2004 елдан №241 "Парламентская газета” кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

27.07.2010 ел. № 210-ФЗ “ Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль канун белән (Россия Федерациясенең кануннар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

07.05.2012 ел. №601-ФЗ Россия Федерациясе Президентының боерыгы белән “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” (алга таба -601нче боерык);

14.04.2008 елдан 264 номерлы ”Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү хокукын алу өчен бәйге уздыру һәм аный килешүнамәне төзү турында” Россия Федерациясенең боерыгы белән (алга таба - 264 нче карар) (15.04.2008 елдан "Российская газета" апрель 2008 г. № 81, 17 апрель 2008 г. № 83, кертелгән үзгәрешләр белән);

”Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү хокукын алу өчен бәйге уздыру һәм аный килешүнамәне төзү турында” Россия Федерациясенең боерыгы белән расланган, сәнәгый һәм яр буе

балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллану турында килешүнамәне әзерләү һәм төзү кагыйдәләре белән (алга таба – 264 нче карар белән расланган Кагыйдәләр) ("Российская газета" 15.04.2008 елдан №81, 17.04.2008 елдан № 83, кертелгән үзгәрешләр белән);

05.12.2005 ел.№563 "Татарстан Республикасы Хөкүмәте -Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Регламентын һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте -Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппараты турында Кагыйдәнамәне раслау турында" Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карары белән ( алга таба – 563 нче карар) (Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карарлары һәм республика башкарма хакимият әгъзаларының норматив актлар җыентыгы, 21.12.2005 ел., № 47-48, кертелгән үзгәрешләр белән);

18.04.2008ел. №246 "Татарстан республикасының хайваннар дөнья-сы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе турында Кагыйдәләрне раслау турында" Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карары. (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының боерыклар һәм карарлар һәм башкарма хакимиятнең республика әгъзаларының норматив актлары җыентыгы, май 2008, № 19,21, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып)( алга таба – Идарә турында Кагыйдәнамә)

02.11.2010 ел. "Татарстан Республикасының башкарма хакимият әгъзаларының хезмәт күрсәтүләре буенча адмистратив регламентларны эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгешләр кертү турында "гы 880 номерлы Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының карары (алга таба –ТР МК880 номерлы карары)(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр һәм республика башкарма хакимият әгъзаларының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46)

1.5. Бу регламентта киләсе атамалар һәм билгеләмәләр кулланыла:

биологик су байлыклары – табигый ирektә булган балыклар, умырткасызлар, суда яшәүче имезүчеләр, суүсемнәр, башка су хайваннары һәм үсемлекләре;

биологик су байлыкларын тоту(табу) - биологик су байлыкларын яшәү тирәлегеннән тартып алу;

балыкчылык - биологик су байлыкларын тоту(табу) буенча эшчәнлек;

сәнәгый балыкчылык (кәсеп)- биологик су байлыкларын тоту, эшкәртү, күчереп төяү, күчерү һәм саклау өчен махсус чаралар кулланып, биологик су байлыкларын тоту(табу) буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге;

биологик су байлыкларын гомуми рөхсәт ителгән тотым (алга таба – ГРТ) кәсеп районында яки балык хуҗалыгы бассейнында конкрет төр биологик су байлыкларын еллык тотуның фәнни нигезләнгән күләме.

техник хата – алар нигезендә мәгълүмат кертелгән документлардагы мәгълүмат белән,кертелгән документтагы(дәүләт хезмәте нәтиҗәсе) мәгълүматның туры килмәвенә китергән, дәүләт хезмәте күрсәтүче әгъза белән җибәрелгән, хата (хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата).

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авылларында гаризачыларга мәгълүмат бирү, документларны кабул итү һәм бирү тәрәзәсе.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләпнең исеме | Стандартка куела торган таләпнең эчтәлеге | Таләпне яки дәүләт хезмәтен билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәтенең атамасы | Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү | 166-ФЗ номерлы Федераль канунның 33.3 маддәсе |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче әгъзаның атамасы | Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе | Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе турында Кагыйдәнамә 4.1.35 пункт |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллану турында Килешүнамә Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллану турында Килешүнамә төзүдән баш тарту | 166-ФЗ номерлы Федераль канунның 33.3 маддәсе |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул санда дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган, оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген, РФ кануннары белән каралган мөмкинлек булган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакытын истә тотып | Бәяләү һәм бәйгедә катнашу гаризаларын туры китерү беркетмәсенә кул куйганнан көнән соң 15 көн эчендә.<br>Әгәр дә бәйгегә 1 катнашучы кертелгән очракта, гаризаларны карау беркетмәсенә кул куйганнан соң 22 көн эчендә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | № 264 карар белән расланган Кагыйдәләр п. 6, 7, 8, 8.1 |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен канун яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә, күрсәтү тәртибе. | Россия Федерациясенең Бюджет кодексы һәм бюджет турындагы канун белән билгеләнгән, Россия Федерациясенең бюджет системасының бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативлары белән туры китереп,<br>бәйге җиңүчесе туры килүче бюджетка күчерергә тиешле түләү кертүне раслый торган документлар (сәнәгый балык тоту бүлемтеген куллану өчен алдан керткән һәм гомуми түләү күләме арасындагы аерма).<br>Бәйге җиңүчесе күчергән акча, сәнәгый балык тоту бүлемтеген куллану өчен түләү булып санала.<br>Документлар, бәйге җиңүчесе белән, электрон имза белән расланып, шулай ук электрон рәвештә, “Интернет” челтәре мәгълүмат ресурслары яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша юнәлтелергә мөмкин. | № 264 карар белән расланган Кагыйдәләр<br>п. 5 (б) |
| 2.6. Дәүләт әгъзалары, җирле үзидарә әгъзалары һәм башка оешмалар<br>карамагындагы, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук гаризачылар белән аларны алу ысуллары, шул | 14.04.2008 елдан 264 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгы белән расланган, Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү хокукын алу өчен бәйгене оештыру һәм уздыру Кагыйдәләре белән каралган, бәйгене бәяләү һәм бәйгедә катнашу гаризаларын туры китерү беркетмәсе.<br>Гариза бирүче тапшырырга тиеш булган документлар исемлеге һәм аларны тапшыру | № 264 карар белән расланган Кагыйдәләр<br>п. 5 (а) |

| | | |
|---|---|---|
| санда электрон рәвештә;<br>кирәкле документлар аларның кулланауында булган дәүләт әгъзалары, җирле үзидарә әгъзалары һәм башка оешмалар. | ысуллары һәм тәртибе, бу Регламентның 2.5. пунктында билгеләнгән.<br>Дәүләт әгъзалары, җирле үзидарә әгъзалары һәм башка оешмалар кулланауында булган, өстә күрсәтелгән документларны, гариза бирүчедән таләп итәргә тыела. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп<br>ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма әгъза тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте әгъзалары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми. | № 264 карар белән расланган Кагыйдәләр п. 3. |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Нигезләр юк | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>1. Бу регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документлар исемлегеннән документны бирмәү.<br>2. Бәйге документлары белән каралган вакыт эчендә, кул куелган килешүнамәне тапшырмау. | № 166-ФЗ Федераль канун;<br>№ 264 карар белән расланган Кагыйдәләр |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре юк. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә: Россия Федерациясенең Бюджет кодексы һәм бюджет турындагы канун белән билгеләнгән, Россия Федерациясенең бюджет системасының бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативлары белән туры китереп, бәйге җиңүчесе туры килүче бюджетка күчерергә тиешле түләү кертүне раслый торган документлар (сәнәгый балык тоту бүлемтеген куллану өчен алдан керткән һәм гомуми түләү күләме арасындагы аерма).<br>Бәйге җиңүчесе күчергән акча, сәнәгый балык тоту бүлемтеген куллану өчен түләү булып санала. | № 264 карар белән расланган Кагыйдәләр п. 5 (б) |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, түләүнең күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре. | Мәҗбүри һәм зарури хезмәтләр таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең | Гариза бирүченең кабул итүне көтү (кабул итү) вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Аерым дәрәҗәдәге дәүләт хезмәтен алучылар өчен чиратлылык билгеләнмәгән. | № 601 боерык |

| | | |
|---|---|---|
| нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап<br>мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты,шул санда электрон рәвештә | Гариза бирү тәртибе каралмаган. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте<br>күрсәтелә торган бүлмәләргә карата<br>таләпләр, шул санда күрсәтелгән объектлар, Россия<br>Федерациясенең инвалидларны иҗтимагый яктан яклау турындагы кануны белән тәңгәл килеп, инвалидлар йөрерлек өчен җайлы булырга тиеш, шулай ук андый хезмәтне күрсәтү турында турыдан-туры күренә торган, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат белән җиһазландырылырга тиеш. | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы һәм янгын сүндерү системасы белән,мәгълүмат стендлары белән,документларны тутыру өчен яраклы булган җиһазлар булган биналарда алып барыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына инвалидлар өчен җайлы керү-чыгу урыннары тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында турыдан-туры күренә торган, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып җиһазландырылырга тиеш. | № 880 карар |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән файдалана<br>алу мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре, шул санда дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза | Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Идарә биналарының җәмәгать траспортына якын булу;<br>гаризалар кабул итәр өчен саны буенча | |

| | | |
|---|---|---|
| бирүченең урындагы затлар белән аралашу саны һәм вакыты, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган, күпфункцияле үзәкләрдә алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган, күпфункцияле үзәкләрнең ераклашкан эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен алу барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге ,шул санда мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланып | җитәрлек белгечләр булу, шулай ук документлар кабул итәр өчен бина булу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүматның “Интернет” челтәре мәгълүмат ресурсларында, мәгълүмат стендларында, Идарәнең рәсми сайтында булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәт-кечләре булып түбәндәгеләр тора<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>Идарә белгечләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышында бу регламентны бозу турында нигезле шикаятьләр булмау;<br>гариза бирүченең Идарә белгечләре белән аралашу саны;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны шәхси тапшырганда - ике тапкырдан да артмаска тиеш (консультацияләрне санамыйча) ;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша яки электрон рәвештә тапшырганда – бердән дә артмаска тиеш.<br>Гариза бирүченең Идарә хезмәткәре белән кабул ителү вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрнең ераклашкан эш урыннарында алу мөмкинлеге юк.<br>Дәүләт хезмәтен алу турында мәгълүматны | |

| | | |
|---|---|---|
| | бәйге җиңүчесе Идарәгә шәхси барып ала. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Бу Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документлар электрон рәвештә бирелергә мөмкин, шул санда Интернет челтәре аша һәм Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул санда административ процедураларны электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре, ә шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торганкүпфункцияле үзәкләрнең ераклашкан эш урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндәге гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы

3.1.1. Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү:

1) Бәйге җиңүчесен консультацияләү;
2) Бәйге җиңүчесе һәи Идарә башлыгы белән килешүнамә төзү;
3) Бәйге җиңүчесенә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру;
4) Техник хатаны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы әлеге административ регламентның 1нче кушымтасында бирелә.

3.2. Бәйге җиңүчесен консультацияләү, шул санда бәйге җиңүчесенә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүдә булышу.

Бәйге җиңүчесе Идарәгә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алырга дип,шул санда гаризаны рәсмиләштерү өчен, телефоннан һәм (яки) электрон почта аша(e-mail: ojm@tatar.ru), Татарстан Республикасының рәсми порталындагы интернет-кабул итү бүлмәсе аша (http://ojm.tatarstan.ru.) һәм шәхси Идарәгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы..

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы Идарә белгече, бәйгедә җиңүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итү формасы һәм башка мәсьәләләр буенча, гаризаны рәсмиләштерергә булыша.

Процедура бәйге җиңүчесе мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу сораулары буенча консультация.

3.3. Идарә белгече, бәяләү һәм бәйгедә катнашу гаризаларын туры китерү беркетмәсенә кул куйганнан көнән соң, 1эш көне эчендә, беркетмәнең 1 нөсхәсен һәм килешүнамәне бәйгедә җиңүчегә кул куярга бирә.

Бу пункт белән каралган процедура, бәяләү беркетмәсенә кул куйганнан һәм бәйгедә катнашу гаризаларын туры китергәннән соң, 1эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: җиңүчегә кул куярга бирелгән килешүнамә.

3.3.1. Бәйгедә җиңүче , бәйге документларында күрсәтелгән вакыт эчендә, кул куелган килешүнамәне һәм Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларны идарә белгеченә тапшыра.

Бәйге документлары белән каралган вакыт эчендә, Идарә белгеченә кул куелган килешүнамәне яки Россия Федерациясенең Бюджет кодексы һәм бюджет турындагы канун белән билгеләнгән, Россия Федерациясенең бюджет системасының бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативлары белән туры китереп, бәйге җиңүчесе туры килүче бюджетка күчерергә тиешле түләү кертүне раслый торган документларны(сәнәгый балык тоту бүлемтеген куллану өчен алдан

керткән һәм гомуми түләү күләме арасындагы аерма) тапшырмаган бәйге җиңүчесе, килешүнамә төзүдән баш тарткан дип санала. Ул очракта бәйге җиңүчесе булып, гаризасына 2нче номер бирелгән катнашучы танылa һәм ул көннән бәйге оештыручы, сәнәгый яки яр буе балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү хокукын алу өчен бәйгене оештыру һәм уздыру Кагыйдәләре белән тәңгәл килеп, аның белән килешүнамә төзи.

Бәйге җиңүчесе яки гаризасына 2нче номер бирелгән катнашучы килешүнамә төзүдән баш тарткан очракта, алдан керткән түләүләре кайтарылмый.

Ул түләү, сәнәгый яки яр буе балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү хокукын алу өчен бәйгене оештыру һәм уздыру Кагыйдәләренең 17 пункты “л” кече пункты белән тәңгәл килеп, Россия Федерациясенең Бюджет кодексы һәм бюджет турындагы канун белән билгеләнгән, Россия Федерациясенең бюджет системасының бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативлары белән туры китереп, бәйге җиңүчесе туры килүче бюджетка күчерелә.

Гаризасына 2нче номер бирелгән катнашучы килешүнамә төзүдән баш тарткан очракта, бәйге уздырылмаган дип игълан ителә, һәм ул көннән алып 6 ай эчендә бәйге оештыручы яңа бәйге уздыра.

Бу пункт белән билгеләнә торган процедура, бәйге җиңүчесе Идарә белгеченә кул куелган килешүнамәне һәм бәйге документларында күрсәтелгән түләү счетына, сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллану өчен, гаризада күрсәтелгән күләмдә, акча күчерүне раслый торган документларны, ә шулай ук реквизитларны тапшырырга тиешле вакыт эчендә тормышка ашырыла. Күрсәтелгән вакыт, бәяләү һәм гаризаларны туры китерү беркетмәсенә кул куйганнан соң, 5 эш көненнән дә ким һәм 10 эш көненнән дә күп булмаска тиеш.

Процедура нәтиҗәсе: бәйге җиңүчесе белән кул куелган килешүнамә.

3.3.2. Идарә башлыгы бәйге җиңүчесеннән алган килешүнамәгә кул куя һәм Идарә бүлегенең белгеченә юнәлтә.

Бу пункт белән билгеләнә торган процедура, бәйге документларында күрсәтелгән вакыт эчендә тормышка ашырыла, ләкин бәйге нәтиҗәләре турында мәгълүматны Интернет челтәрендә торглар уздыру турында мәгълүматларны урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында www.torgi.gov.ru урнаштырган көннән соң,10 эш көненнән дә иртә булмаска тиеш.

Процедура нәтиҗәсе: Идарә башлыгы белән кул куелган килешүнамә.

3.4. Бәйгегә 1 генә катнашучы кертелгән очракта ( алга таба – бәйгенең бердән бер катнашучысы) Идарә белгече, бәяләү һәм гаризаларны туры китерү беркетмәсенә кул куйганнан соң, 10 эш көне эчендә, аңа килешүнамә проектын кул куярга бирә.

Бу пункт белән билгеләнә торган процедура, бәяләү һәм гаризаларны туры китерү беркетмәсенә кул куйганнан соң, 10 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: бәйгенең бердән бер катнашучысына имза куярга килешүнамәне юнәлтү.

3.4.1. Бәйгенең бердән бер катнашучысы, комиссия карар кабул иткәннән соң 10 көн эчендә, килешүнамәгә кул куя һәм Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларны идарә белгеченә тапшыра.

Бу пункт белән каралган процедура комиссия карар кабул иткәннән соң 10 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бәйгенең бердән бер катнашучысы белән кул куелган һәм Идарә белгеченә тапшырылган килешүнамә.

3.4.2. Идарә башлыгы бәйгенең бердән бер катнашучысыннын алган килешүнамәгә кул куя һәм Идарә бүлегенең белгеченә юнәлтә.

Бу пункт белән билгеләнә торган процедура, бәяләү һәм гаризаларны туры китерү беркетмәсенә кул куйганнан соң, килешүнамәне һәм Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң, 10 эш көне эчендә башкарыла, ләкин бәяләү һәм гаризаларны туры китерү беркетмәсен Идарәнең рәсми сайтында урнаштырганнан соң 10 эш көненнән дә ким булмаска тиеш.

Процедура нәтиҗәсе: Идарә башлыгы белән кул куелган килешүнамә.

3.5. Идарә белгече бәйге җиңүчесенә яки бәйгенең бердән бер катнашучысына, Идарәнең килешүнамәне раславы турында хәбәр итә.

Бу пункт белән билгеләнә торган процедура, Идарә башлыгы килешүнамәгә кул куйганнан соң, 1 эш көнендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: килешүнамәнең раслануы турында хәбәр ителгән бәйге җиңүчесе яки бәйгенең бердән бер катнашучысы.

3.6. Идарә белгече бәйге җиңүчесенә яки бәйгенең бердән бер катнашучысына килешүнамәнең икенче нөсхәсен тапшыра.

Бу пункт белән билгеләнә торган процедура, гариза бирүче килгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: сәнәгый балык тоту бүлемтегeн бирү турында, тапшырылган килешүнамә

3.7. Техник хатаны төзәтү ( хәреф хатасы яки арифметик хата):

Килешүнамәне яңадан төзү, элек бирелгән килешүнамәдә җибәрелгән, техник хатаны төзәтү (хәреф хатасы яки арифметик хата) белән бәйле рәвештә үтәлә.

Килешүнамәне яңадан төзү, техник хатаны төзәтү турында теркәлгән гариза һәм аңа кушылган хаталы килешүнамә нигезендә үтәлә.( гаризаның формасы бу регламентның 2нче кушамтасында бирелде)

3.7.1. Бүлек белгече:

- гаризаны кабул итә һәм терки;

- гариза бирүчегә,документларны кабул итү вакытын һәм бирелгән номеры күрсәтеп, гаризаның күчермәсен тапшыра яки почта яки электрон почта аша( аның теләве буенча) юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедуралар, гариза теркәлгән көнне башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.7.2. Бүлек белгече:

- килешүнамәне яңадан ясый;

- килешүнамәне яңадан төзү турында гариза бирүчегә хат проектын әзерли һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедуралар, гариза Идарә белгеченә җибәрелгәннән соң, бер эш көне эчендә башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына юнәлтелгән өземтә.

3.7.3. Бүлек башлыгы әзерләнгән килешүнамәнең дөреслеген тикшерә, хат проектын яраштыра һәм аларны Идарә башлыгына юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, Идарә башлыгына яраштырырга юнәлтелгән килешүнамә һәм хат проекты кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Идарә башлыгына яраштырырга юнәлтелгән килешүнамә һәм хат проекты.

3.7.4. Идарә башлыгы хат проектын һәм аңа куелган килешүнамәгә кул куя һәм Бүлеккә юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: яраштырылган хат проекты һәм килешүнамә.

3.7.5. Идарә белгече , Идарә башлыгы белән кул куелган, дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы хатны рәсмиләштерә, һәм килешүнамә белән бергә гариза бирүчегә яки аның вәкаләтле затына(ышанычнамә булса) имза астына тапшыра.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, гариза бирүче яки аның вәкаләтле заты килгәннә соң, бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән хат һәм техник хаталары төзәтелгән килешүнамә.

3.8. Күп функцияле үзәк аша дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе, КПҮ ераклашкан эш урыны.

Дәүләт хезмәте ( шул санда дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гаризаны тапшыру) күп функцияле үзәк, КПҮ ераклашкан эш урыны аша күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшерү формалары һәм тәртибе

4.1. Җаваплы затлар белән, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында , бу регламентның кагыйдәләрен һәм башка норматив-хокукый актларны тотуны һәм саклаун, ә шулай ук җаваплы затлар белән карарлар кабул итүне тикшерү Идарә башлыгы белән үткәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү, тикшерүләр уздыруны, урындагы затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьле гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләрен карау, алар буенча карар кабул итүне һәм җавап әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне саклау артыннан тикшерү рәвешләре:

эш башкаруны алып бару;

каралган документларның нәтиҗәсе бу регламентның таләпләренә туры килүе;

документларны кабул итү вакытын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, аның нәтиҗәсен бирү вакытын һәм тәртибен саклау.

Тикшерүләрне уздыруның кабатлануы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш ( гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) характер йөртә.

4.2. Тикшерүләрне уздыру нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыклаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар, Россия Федерациясе кануннары белән каралган тәртиптә җаваплылыкка тарттырылалар.

4.3. Гариза бирүчеләр ягыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү артыннан тикшерү,

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольдә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Идарәнең ачык эшчәнлегендә, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алганда һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлегендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче әгъзаның , ә шулай ук аның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Бүлек белгече, Бүлек башлыгы, Идарәнең район хезмәткәрләренә гамәлләрен (гамьсезлеген) судка кадәрге тәртиптә Идарә башлыгына шикаять кылу хокукына ия. Идарә башлыгы белән кабул ителгән карарларга шикаять Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны теркәү срогы бозылу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы бозылу;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп итү;

4) гариза бирүчедән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тартуның нигезләре федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп итү;

7) Идарәнең вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яки андый төзәтүләр өчен билгеләнгән срокның бозылуы.

5.2. Шикаять Идарәгә язмача яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, күп функцияле үзәк аша, электрон почта аша(e-mail:ojm.tatar.ru), яки электрон документ рәвешендә “Интернет” челтәрен кулланып, Идарәнең рәсми сайтына (http://ojm.tatar.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru), Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы(http://uslugi.tatar.ru) аша, ә шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырыла ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәүдән соң 15 эш көне эчендә, һәм Идарәнең дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларны кабул итүдә яки ясалган хаталарны төзәтүдә яки андый төзәтүләрне ясау срогы бозылу очрагында кире кагуга шикаять биргән очракта – аны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә.

Шикаятьне канәгатьләндерү яки кире кагу турында карарны кабул иткән көннән соңармыйча, гариза бирүчегә язмача яки гариза бирүченең теләге буенча, электрон рәвештә, шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап

җибәрелә.

5.4. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1)Идарәнең исеме, гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаять бирелә торган, Идарәнең дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи заты исеме, фамилиясе, атасының исеме;

2) гариза бирүче-физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, гариза бирүче –юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, һәм шулай ук гаризачыга җавап бирү өчен элемтә телефонының номеры (номерлары), (булган очракта) электрон почта һәм почта адресы (адреслары);

3) Идарәнең, Идарәнең вазыйфаи затның шикаять кылына торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) турында белешмәләр;

4) Идарәнең вазыйфаи затының карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) белән килешмәве буенча гаризачы тарафыннан китерелгән дәлилләр.

5.5 Шикаятькә, анда күрсәтелгән шартларны дәлилли торган, документларның күчермәсе теркәлергә мөмкин. Андый очракта шикаятьтә, аңа теркәлгән документларның исемлеге куела.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча , Идарә башлыгы ( Идарә башлыгының урынбасары), түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

шикаятьне, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүче  әгъза тарафыннан кабул телгән карарны кире кагу, җибәрелгән хаталарны төзәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм җитешсезлекләрне төзәтү, аларны алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, әлеге Регламент белән каралмаган акча чараларын гаризачыга кайтарып бирү формасында, һәм шулай ук бүтән формаларда канәгатьләндерә;

шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

Регламентның 5.3. пунктында күрсәтелгән,  карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча гаризачыга язмача формада һәм гаризачының ихтыяры белән электрон формада шикаятьне карау буенча мотивлаштырылган җавап юнәлтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәсендә административ хокук бозылу яисә җинаять кылу билгеләре ачыкланса, Идарәнең шикаятьне карау вәкаләтләре белән вәкаләтләнгән вазыйфаи заты кичекмәстән бар булган материалларны прокуратура әгъзаларына юнәлтә.

Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен,
балык тоту бүлемтекләрен куллануга
килешүнамә төзү буенча
дәүләт хезмәтен күрсәтүнең
Административ регламентына
1нче кушымта

## Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә эш тәртибенең блок-схемасы

Бәйге җиңүчесен консультацияләү

Идарә белгече бәйге җиңүчесенә консультация бирә. Җиңүче мөрәҗәгать иткән көнне

Килешүнамә проектын , кул кую өчен, җиңүчегә әзерләү һәм тапшыруһәм биңүче белән килешүнамәгә кул кую.
Бәяләү һәм бәйгедә катнашу гаризаларын туры китерү беркетмәсенә кул куйганнан көнән соң 1 көн эчендә

Бәйгедә җиңүче , бәйге документларында күрсәтелгән вакыт эчендә, кул куелган килешүнамәне һәм Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларны идарә белгеченә тапшыра.

Идарә башлыгы белән кул куелган килешүнамә. Бәйге документларында күрсәтелгән вакыт эчендә тормышка ашырыла, ләкин бәйге нәтиҗәләре турында мәгълүматны Интернет челтәрендә торглар уздыру турында мәгълүматларны урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында www.torgi.gov.ru урнаштырган көннән соң,10 эш көненнән дә иртә булмаска тиеш.

Бер генә катнашучы кертелсә.

Подготовка и передача проекта договора на подписание единственному участнику конкурса. В течение 10 рабочих дней с даты подписания протокола рассмотрения заявок

Бәйгенең бердән бер катнашучысы, комиссия карар кабул иткәннән соң 10 көн эчендә, килешүнамәгә кул куя һәм Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларны идарә белгеченә тапшыра.

Бәйгенең бердән бер катнашучысы белән Идарә башлыгының килешүнамә төзүе. Килешүнамәне һәм Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң, 10 көн эчендә, ләкин бәяләү һәм гаризаларны туры китерү беркетмәсен Идарәнең рәсми сайтында урнаштырганнан соң 10 эш көненнән дә ким булмаска тиеш.

Бәйге җиңүчесенә яки бәйгенең бердән бер катнашучысына килешүнамәгә имза куелганы турында хәбәр итү. Идарә башлыгы килешүнамәгә кул куйганнан соң 1 эш көне эчендә.

Бәйге җиңүчесенә яки бәйгенең бердән бер катнашучысына килешүнамәнең икенче нөсхәсен тапшыру.

Техник хатаны төзәтү. Бәйге җиңүчесенә яки бәйгенең бердән бер катнашучысына төзәтелгән килешүнамәнең икенче нөсхәсен тапшыру. 5 эш көне эчендә.

Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен,
балык тоту бүлемтекләрен куллануга
килешүнамә төзү буенча
дәүләт хезмәтен күрсәтүнең
Административ регламентына
2 нче кушымта

Татарстан республикасының
хайваннар дөньясы объектларын
саклау һәм файдалану Идарәсе
башлыгына
______________________________
(Ф.И.О.)
______________________________
(физик затлар өчен: Ф.И.О.,
адрес (почта һәм(яки)электрон)
_____________________________
Юридик затлар өчен: оешманың исеме,
адрес (почта һәм(яки)электрон)

**Техник хатаны төзәтү турында гариза.**

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документны төзегәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

______________________________________________________________________________
(бирелгән документ)
________________________________________________________________________________курсәтелгән.

Дөрес мәгълүматлар:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документны төзегәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм ул үзгәрешләрне документка кертүегезне сорыйм.

Киләсе документларны терким:
1. __________________________________________________________
2.___________________________________________________________

Яңадан төзелгән килешүнамәнең әзерлеге турында хәбәр итүегезне сорыйм.
____________________________________________________________________
(шәхси яки адресны күрсәтеп, почта аша)

"___"__________ 20___ ел. ____________________________________
(гариза бирүченең имзасы) (имзаны чишү)

Сәнәгый балык тотуны булдыру өчен, балык тоту бүлемтекләрен куллануга килешүнамә төзү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына кушымта (белешмә)

Биологик су байлыкларын куллануга килешүнамә төзү буенча, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның һәм әгъзаларның реквизитлары

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Идарә башлыгы | 211-66-94 | Fjodor.Batkov@tatar.ru |
| Начальник отдела лицензияләү бүлеге башлыгы | 211-69-07 | Rinat.Chispyakov@tatar.ru |
| Лицензияләү бүлеге белгечләре | 211-70-78 | Yuriy.Pavlov@tatar.ru |
| | | Albina.Galiakberova@tatar.ru |
| | | Roza.Minnegulova@tatar.ru |

Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларын, табигый байлыкларны куллану һәм тирә якны саклау сораулары буенча бүлек башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |
| Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппаратының экология һәм табигатьне куллану бүлегенең баш киңәшчесе | 264-76-35 | Olga.Matveeva@tatar.ru |
| Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппаратының экология һәм табигатьне куллану бүлегенең баш киңәшчесе | 264-76-35 | Ekaterina.Filinova@tatar.ru |